МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

17.05.2021 г.Казань № 313

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 15 июнендә 7721 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгын рәсмиләштерү һәм бирү тәртибе турында» 2012 елның 4 сентябрендәге 697 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгын рәсмиләштерү һәм бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгын рәсмиләштерү һәм бирү эшен камилләштерү максатларында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгын рәсмиләштерү һәм бирү тәртибе турында» 2012 елның 4 сентябрендәге 697 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2013 елның 16 сентябрендәге 529 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгын рәсмиләштерү һәм бирү тәртибенә үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә (кушымтада бирелә) бәян итәргә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2012 елның 4 сентябрендәге 697 номерлы боерыгы белән расланды
(Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2021 елның 17 маендагы 313 номерлы боерыгы редакциясендә)

## Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгын рәсмиләштерү һәм бирү тәртибе

1. Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгын рәсмиләштерү һәм бирүнең әлеге тәртибе Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгын рәсмиләштерү һәм бирү кагыйдәләрен билгели.

2. Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгы, уллыкка алынганнарын да кертеп, фактта үзләре белән яши торган 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк баласы булган ата-ананың берсенә (алга таба – мөрәҗәгать итүче) Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән очракта яки тору урыны буенча теркәлгән очракта (яшәү урыны буенча теркәлмәгән булса) бирелә.

Күпбалалы гаилә составында ир белән хатын, әлеге гаиләдә фактта яши һәм тәрбияләнә торган балалар (18 яшенә җитмәгән затлар), шул исәптән уллыкка (кызлыкка) алынган, үги уллар һәм үги кызлар, шулай ук белем алуына бәйле рәвештә ата-анасыннан читтә яши торган балалар (18 яшенә җитмәгән затлар) исәпкә алына.

Күпбалалы гаилә таныклыгы мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмаган очракта бирелә.

3. Күпбалалы гаилә таныклыгы Татарстан Республикасының бөтен территориясендә гамәлдә һәм, гаилә яшәү урынын алыштырган очракта, Татарстан Республикасы чикләрендә үз көчен саклый.

4. Күпбалалы гаилә таныклыгын алу өчен мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының гаиләнең фактта яшәгән урыны буенча Социаль яклау идарәсенә (бүлегенә) (алга таба – Идарә (бүлек)) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы раслаган форма буенча, гаилә составын һәм гаиләнең фактта яшәгән урынын күрсәтеп, күпбалалы гаилә таныклыгы бирү турында гариза һәм үзендә булган тормыш хәлләренә бәйле рәвештә түбәндәге документларны тапшыра:

баланың тууын теркәү турындагы таныклыкның чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе;

чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән гаилә коруны теркәү турында таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе;

аерылышу турында чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе;

граждан хәле актларын теркәү органы яисә Россия Федерациясе консуллык учреждениесе тарафыннан бирелгән уллыкка алу турында таныклык күчермәсе;

белем алуына бәйле рәвештә ата-анасыннан читтә яши торган, 18 яшенә җитмәгән затлар өчен чит ил территориясендә бирелгән, Россия Федерациясеннән читтә белем алу турында документ күчермәсе һәм аның нотариаль таныкланган рус теленә тәрҗемәсе;

ир белән хатынның икенчесеннән түбәндәгеләрне раслый торган документ:

аларның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык булуын;

шәхси мәгълүматларны органга яисә оешмага тапшырганда мөрәҗәгать итүченең алар исеменнән эш кылуга вәкаләтле булуын. Ирнең яисә хатынның имзасы Идарә (бүлек) белгече тарафыннан, нотариаль рәвештә яки Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 185[1] статьясының 2 пунктында һәм Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 53 статьясының 2 өлешендә күрсәтелгән оешмалар һәм учреждениеләр тарафыннан таныклана;

мөрәҗәгать итүченең 3х4 см үлчәмендәге фотолары.

Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Идарә (бүлек) белгече тарафыннан таныклана. Документларның күчермәләре берәр нөсхәдә тапшырыла.

Гариза Идарәгә (бүлеккә) почта буенча җибәрелергә мөмкин. Бу очракта гаризага документларның Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган күчермәләре теркәлә.

Гариза Идарәгә (бүлеккә), фотоны таныклык алганда тапшырып, «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган (таныкланган) электрон документлар формасында электрон чаралардан һәм (яки), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша җибәрелергә мөмкин.

5. Идарә (бүлек) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә, шул исәптән электрон формада да, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып, вәкаләтле оешмалардан түбәндәге мәгълүматларны ала:

бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында;

гаилә коруны (аерылышуны) дәүләт теркәвенә алу турында;

Россия Федерациясе чикләрендә яшәү (тору) урыны буенча теркәлү яисә теркәлмәү турында;

ата-ана хокукыннан мәхрүм ителү турында;

18 яшенә җитмәгән, белем алуына бәйле рәвештә ата-анасыннан аерым яши

торган затлар өчен баланың белем алуы турында;

салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле бурычларның булмавы турында.

Әлеге Тәртипнең әлеге пунктында күрсәтелгән белешмәләре булган документларны мөрәҗәгать итүчеләр, аларның законлы вәкилләре яки ышанычлы затлар Идарәгә (бүлеккә) үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы.

6. Күпбалалы гаилә таныклыгы бирү (бирүдән баш тарту) турында карар Идарә (бүлек) тарафыннан күпбалалы гаилә таныклыгы бирү турындагы гаризаны теркәгәннән соң 10 эш көне эчендә кабул ителә.

Күпбалалы гаилә таныклыгын бирү (бирүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турындагы белдерү мөрәҗәгать итүчегә күпбалалы гаилә таныклыгы бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән башлап бер эш көне эчендә гаризада күрсәтелгән ысул белән (язма рәвештә, почта адресы буенча, электрон документ формасында электрон почта адресына, телефон аша смс-хәбәр итеп) җибәрелә.

7. Күпбалалы гаилә таныклыгы бирүдән баш тарту нигезләре булып түбәндәгеләр тора:

әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендәге документның тапшырылмавы;

дөрес булмаган белешмәләре булган документларның тапшырылуы;

мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы территориясендә яшәгән урыны буенча теркәлмәве яки торган урыны буенча (яшәгән урыны буенча теркәлмәгән очракта) теркәлмәве;

мөрәҗәгать итүчедә салымнар, җыемнар һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булуы;

гаиләдә 18 яшькә кадәр өчтән азрак бала булуы;

мөрәҗәгать итүченең ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән булуы.

8. Күпбалалы гаилә таныклыгы, аны бирү датасын һәм аның гамәлдә булу вакытын күрсәтеп, Идарә (бүлек) җитәкчесе тарафыннан имзалана һәм мөһер белән таныклана.

Күпбалалы гаилә таныклыгының гамәлдә булу срогы гаилә күпбалалы гаилә статусын югалткан очракта, шул исәптән кече яшьтәге өч баланың берәрсе 18 яшенә җиткәндә туктатыла.

9. Күпбалалы гаилә таныклыгы мөрәҗәгать итүчегә күпбалалы гаилә таныклыгы бирү турында белдерү җибәрелгәннән соң, мөрәҗәгать итүче әзер күпбалалы гаилә таныклыгын алырга дип килгән көнне тапшырыла.

Гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) Идарәгә (бүлеккә) электрон документлар рәвешендә җибәрелгән очракта, күпбалалы гаилә таныклыгы мөрәҗәгать итүче үзенең фотосы белән мөрәҗәгать иткән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча бирелә.

Бирелә торган күпбалалы гаилә таныклыклары Идарә (бүлек) белгечләре тарафыннан күпбалалы гаилә таныклыкларын исәпкә алу журналында теркәлә һәм мөрәҗәгать итүчегә әлеге журналда имза куйдыртып бирелә.

10. Күпбалалы гаилә таныклыгының гамәлдә булу срогы мөрәҗәгать итүче гаиләсендә бала туганда (уллыкка алынганда) күпбалалы гаилә таныклыгы гамәлдә

булган чорда озайтыла.

Күпбалалы гаилә таныклыгының гамәлдә булу вакытын озайту өчен мөрәҗәгать итүче аның гамәлдә булу вакытын озайту турындагы гариза белән фактта яшәү урыны буенча Идарәгә (бүлеккә) мөрәҗәгать итә һәм күпбалалы гаилә таныклыгы белән әлеге Тәртипнең 4 пунктындагы җиденче-тугызынчы абзацларында күрсәтелгән документны тапшыра.

Туу турында документ чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан яисә уллыкка алу турында таныклык граждан хәле актларын теркәү органы яисә Россия Федерациясе консуллык учреждениесе тарафыннан бирелгән очракта, мөрәҗәгать итүче өстәмә рәвештә әлеге документларның күчермәләрен тапшыра.

Күпбалалы гаилә таныклыгының гамәлдә булу вакытын озайту турындагы гаризаны карау, аның гамәлдә булу вакытын озайту турында карар кабул итү һәм әлеге пунктның җайга салынмаган өлешендә аның гамәлдә булуының яңа срогы турында теркәлгән язулы күпбалалы гаилә таныклыгын бирү күпбалалы гаилә таныклыгын рәсмиләштерү һәм бирү өчен каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

11. Күпбалалы гаилә таныклыгы югалган яки бозылган очракта, ата-ананың (уллыкка алучыларның) берсенең гаризасы буенча «дубликат» тамгасы белән күпбалалы гаилә таныклыгы дубликаты бирелә. Гаризада күпбалалы гаилә таныклыгын алыштыру сәбәпләре күрсәтелә.

Күпбалалы гаилә таныклыгы дубликатын бирү турындагы гаризаны карау, күпбалалы гаилә таныклыгы дубликатын бирү турында карар кабул итү һәм күпбалалы гаилә таныклыгы дубликатын тапшыру күпбалалы гаилә таныклыгын рәсмиләштерү һәм бирү өчен каралган тәртиптә башкарыла.

12. Гаилә әгъзаларының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме алмаштырылган очракта, гаилә әгъзалары вафат булса, ата-ананың гаилә хәле үзгәргән очракта, күпбалалы гаилә таныклыгын алу буенча мөрәҗәгать итү өчен каралган тәртиптә мөрәҗәгать итүче, моңа кадәр бирелгән күпбалалы гаилә таныклыгын өстәмә рәвештә теркәп, күпбалалы гаилә таныклыгы бирү турында гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

13. Идарә (бүлек) мөрәҗәгать итүче тапшырган документларның чынлыгын, аларда булган белешмәләрнең тулылыгын һәм дөреслеген тикшерергә хокуклы.

14. Күпбалалы гаилә таныклыклары бланклары катгый исәпкә алу һәм хисаплылык бланклары өчен билгеләнгән тәртиптә исәпкә алына һәм саклана.